СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

## КАРАРЫ

**19 октябрь 2020 ел** **№10**

**Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Ташкичү авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылында Иске Ашыт авылы, Мәктәп урамы, 4 нчы йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 11 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылында Иске Ашыт авылы, Мәктәп урамы, 4 нчы йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 11 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1 нче этап: Үзәк, Мәктәп урамнарында яшәүчеләр

2 нче этап: С. Халиков урамында яшәүчеләр

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәгемәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән, 1 нче һәм 2 нче төркем инва-

лидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Материал сатып алу һәм зират коймаларын ремонтлау.
- Материал сатып алу һәм «Салават» чишмәсен ремонтлау.
- Урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.
- Рөхсәтсез чүплекне юк итү.
- Уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.
- Су кудыру скважинасына насос сатып алу (2 данә).
- Амкадор хезмәтенә түләү
- Үзәк урамда авария арматуралары өчен тимер-бетон бoжралар куеп, 600 метр сууткәргеч челтәренә ремонт ясау .
- җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең машиналар йөрү өлешен тигезләү һәм түшәү өчен вак таш сатып алу:
  - Үзәк, С. Халиков, Мәктәп урамнары

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Иске Ашыт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендына ТР, Арча районы, Иске Ашыт авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Фәйзуллин